ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 декабрь 2019ел № 6661

Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5586 номерлы карары белән расланган «2020-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә «Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | 1. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү өчен инфраструктураны үстерү.<br>2. Кече һәм урта эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү.<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ каршылыкларны киметү.<br>4. Белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру.<br>5. Кооперация элемтәләрен үстерү. |

2) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Эшмәкәрлек активлыгын күтәрү һәм шәһәр икътисадының ярдәм таләп итә торган өлкәләрендә эшлекле климатны яхшырту максатында төп өстенлекле юнәлешләр билгеләнде:

- эшкәртү производстволары;
- инновацион эшчәнлек;
- халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;
- мәгариф;
- сәламәтлек саклау;
- физкультура һәм спорт;
- мәдәният;
- җәмәгать туклануы;
- эчке туризм.»

3) 3 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Программаның төп максаты һәм бурычлары

Программаның максаты булып эшмәкәрлекнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре тарафыннан җитештерелә торган продукция күләмендә КУЭ субъектлары җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) өлешен арттыру өчен шартлар тудыру тора.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны хәл итәргә кирәк:

- КУЭга ярдәм күрсәтү өчен инфраструктураны үстерү;
- КУЭ, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү;
- КУЭны үстерүдә административ каршылыкларны киметү;
- белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру;
- кооперация элемтәләрен үстерү.

4) 4 бүлеккә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 нче бурычны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү»;

- 5 нче юлда төп чараның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектларына республика һәм федераль ярдәм программалары буенча конкурсларда катнашу буенча мәгълүмат бирү»;

- 6 нчы юлда төп чараның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектларына шәһәрдә, башка шәһәрләрдә, илләрдә үткәрелә торган эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле чаралар (семинарлар, конкурслар, күргәзмәләр, мастер-класслар) турында мәгълүмат бирү»;

- 4 нче бурычны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 нче бурыч. Белем бирүдә ярдәм күрсәтү һәм эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин